**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЕГОРЬЕВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
422621 Каип авылы,
Үзәк урамы, 50 нчы йорт,
тел: 3-36-19

**ГЛАВА ЕГОРЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422621 с.Каипы,
ул. Центральная, д.50
тел: 3-36-19

**2024 елның 11 сентябре** **14 номер**

# БОЕРЫК

**Кадастр номерлары 16:24:070201:1552 булган җир кишәрлекләреннән яисә капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы боерык проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 маддәсе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Егорьево авыл җирлеге уставы, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Егорьево авыл җирлеге советының 2018 елның 12 декабрендәге 41 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Егорьево авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә нигезендә, тормыш эшчәнлегенең уңайлы шартларына кеше хокукларын, җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында, КАРАР БИРӘМ:

1. Кадастр номерлары 16:24:070201:1552 булган җир кишәрлекләреннән яисә капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә,ТР, Лаеш районы, Егорьево авыл җирлеге, Каип авылы, Яшьләр ур. ,мәйданы: 1000 кв. м..,. «Шәхси торак төзелеше өчен» нән “Кибетләр”гә төренә рөхсәт бирү буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.

2. Билгеләргә:

2.1. Үткәрү датасы һәм вакыты –2024 елның 11 октябре 09.00 сәгатьтә.

2.2 Уздыру урыны – Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Егорьево авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы, адресы: 422621, Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Каип авылы, Үзәк урам, зд. 50.

3. Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы

боерык проекты буенча тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Егорьево авыл җирлеге башкарма комитетына тапшырырга, ул түбәндәге адрес буенча урнашкан: 422626, Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Каип авылы, Үзәк урам, зд. 50..

2.4 Чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар бирү вакыты 2024 елның 11 октябренә кадәр.

3. Әлеге карарны «Кама ягы» («Камская новь») район газетасында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Егорьево авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Егорьево авыл җирлеге башлыгы**
**вазыйфаларын башкаручы** **И.Б.Зарипов**